МӘШӘКАТЕ КИМИ

Онлайн документның булса, кәгазен үзең белән йөртергә кирәкме?

> 3

ЛИЛИЯ АППАКОВА:

«Сәхнәдән оятсыз анекдот сөйләү – кыргыйлык»

> 3

БОЗ ҺӘМ КӘШӘКӘ

Татарстан ислам илләрен хоккей уйнарга өйрәтәчәк

> 4

ЛИСИЧАНСК ҮЗГӘРТӘ

Махсус хәрби операция зонасында эшләп кайткан табиб Искәндәр Нурмиев анда күргәннәре турында

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 7 (28974) | Чәршәмбе | 18 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӨРЕП КАБАСЫ

Яшәргә өйрәнәбез

«Мобилизациянең яңа дулкыны булачак. Якыныңның анда әлегәчәк ир-егетләр исемлегендә бармы-юкмы икәнлеген тиз арада ачыкларга ярдәм итәм». Соңгы арада «Телеграм»да шундый игъланнар күренә башлады. Бар нәрсәдән үзенә файда табып калырга тырышкан мошенниклар шул рәвешле илдә барган вакыйгалардан тагын бер кат отып калмакчы.

rg.ru

«Тагын бер кат» диюебез юкка түгел. Хәтерләсәгез, илдә өлешчә мобилизация игълан ителү белән «мобилизациядән качып калырга ярдәм итәм», «военкомат белән проблемалардан коткарам»ише вәгъдәләр белән халыкның башын бутарга кереште алар.

Кибербелгечләр кырыгалдарлар, өлешчә мобилизацияне сәбәп итеп, «Телеграм» мессенджеры аша Россия халкына «һөҗүм итә» башлады дип кисәтә. «РТК-Солар» цифрлы куркынычларны анализлау төркеме җитәкчесе Диана Селехина сүзләренә караганда, кырыгалдарларның кармагына капкан кеше үз артыннан якыннарын, таныш-белешләрен дә өстери. Ник дигәндә, кырыгалдарга акча күчереп, мобилизацияләнәчәк кешеләр исемлеген карыйм дип, ул җибәргән сылтама буенча кергән кеше автомат рәвештә телефонында сакланган башка кешеләрнең номерларына да юл ача. Шул рәвешле аларның да кырыгалдар корбанына әверелүе бик ихтимал.

«Шуңа күрә чит номердан шалтыраткан, язган кеше никадәр генә ышандырырлык итеп сөйләсә дә, аңа ышанырга, ул кушканнарны эшләргә, ул җибәргән сылтамаларга керергә ярамый», – ди Диана Селехина.

Кырыгалдарлар Яңа ел ялларында да тик ятмаган. Рәсми мәгълүматларга караганда, бу чорда илдә мошенниклар тарафыннан алданучылар саны икеләтә арткан. Алар бәйрәм көннәрендә халыкны, нигездә, лотереяда оттыгыз дип, шулай ук бәйрәм чараларына ташламалы бәядән билет «сатып», төп башына утырткан.

Мошенниклар элек-электән яратып кулланган алдау очракларын да онытып бетерми. Халыкны телефон аша төп башына утырту – шулар арасында иң киң таралганы. Рәсми саннардан аңлашылганча, узган ел Россиядә телефон аша кылынган җинаятьләр саны 80 процентка арткан.

Россия Үзәк банкының Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Шәрифуллин сүзләренә караганда, мошенниклар бүген дә, нигездә, банк хезмәткәре булып шалтырата. Сезнең счеттан акча урларга җыеналар, моның өчен акчагызны куркынычсыз счетка күчереп өлгерергә кирәк, дип алдый алар. Ышанычны арттыру өчен соңгы арада корбанына шушы банкның хезмәткәре булуын «раслаган» ялган таныклык, документлар да җибәрә башлаган алар.

– Анда дөрестән дә бездә эшләүче кешенең исем-фамилиясе күрсәтелгән булуы ихтимал. Ник дигәндә, ул мәгълүматны табу кыен түгел. Аны безнең сайтка кергән һәркем күрә ала. Шуңа күрә тагын бер кат искәртәсем килә: банк хезмәткәре беркайчан да кешегә турыдан-туры шалтыратмаячак. Телефон аша аларның исәп-хисап счетлары белән дә эш алып бармый ул. Ышандыру өчен, ниндидер документ күчермәләрен дә җибәрми. Шуңа күрә мондый шикле шалтырату килеп ирешсә, сөйләшүне шундук туктатыгыз. Исәп-хисап счетыгыздагы акча өчен борчылсагыз, бу хакта банкның үзенә шалтыратып белешегез. Аның номеры банк картагызның арткы ягында күрсәтелгән, – ди Марат Шәрифуллин.

Юрист Роман Архипов сүзләренә караганда, мошенник сүзенә алданып рәсмиләштерелгән кредиттан баш тартып та булмый.

– Кредиттан баш тарту алган акчаны банкка кире кайтару дигәнне аңлата. Әмма акчасы мошенник кулында булгач, алданган кеше бу акчаны ничек кире кайтарсын? Башка очракларда банктан алган кредиттан баш тартып була. Моны сезгә кредит хупланган көннән башлап 14 көн эчендә эшләргә була. Әмма аны никадәр тизрәк эшләсәгез, шулкадәр яхшырак. Моның өчен банкка, кредиттан баш тартып, алган акчаны кире кайтарырга җыенуыгызны белгертеп, гариза язарга кирәк. Банк бу мөрәҗәгатьне бер атна эчендә карарга тиеш. Финанс оешмасы теге яки бу сәбәпләр аркасында сезнең белән килешүне өзүдән баш тартса, судка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – ди юрист.

Банктан дип шалтыраткан мошенниклар корбаны булмас өчен хокук сакчылары түбәндәге киңәшләргә колак салырга чакыра:

- банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчагызны югалтырга мөмкинсез дип, куркытып шалтыратмый;
- алар клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләр дә сорамый;
- банк хезмәткәре башта кредит рәсмиләштереп, аннары шуны ниндидер билгесез счетларга күчерүне сорамый;
- телефоннан шалтыраткан «банк хезмәткәре» кушуы буенча телефоныгызга ниндидер кушымталар йөкләтүдән дә сакланыгыз;
- үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны беркемгә дә хәбәр итмәгез;
- сезгә чынлыкта кемнең шалтыратуын банкның «кайнар элемтәсе»нә шалтыратып белешегез. Аның номеры банк картасының арткы ягында күрсәтелә. Эчке эшләр органнарына да мөрәҗәгать итү комачауламас.

Фаразлаганнан яхшырак

Узган елда Россиядә икътисадый үсеш фаразланганнан яхшырак булды. Икътисадый мәсьәләләр буенча киңәшмәдә ил Президенты Владимир Путин белдергәнчә, 2022 елда илдә тулай эчке продукт күләме нибары 2,5 процентка кимегән. Шул ук вакытта кайбер белгечләр аның 20 процентка кадәр азаерга мөмкин булуын гоманлаган. Президент шулай ук халыкның мәшгульлеген арттыру һәм хезмәт хакларын үстерүгә этәргеч бирергә кушкан. «Ил азагында күзәтелгән икътисадый үсеш тенденциясен сакларга һәм көчәйтергә кирәк», – дигән ул.

Армия үзгәреш көтә

Россия Кораллы Көчләрендә зур үзгәрешләр булачак. Аерым алганда, 2023–2026 елларда аларның сафы ишәеп, 1,5 миллион кешегә җитәчәк.

«РИА Новости» хәбәренә караганда, тагын ике – Мәскәү һәм Ленинград хәрби округларын оештыру күздә тотыла. Шулай ук илнең яңа төбәкләрендә әзерлекле гаскәрләр төркемнәре булдырылачак, Хәрби-диңгез флоты, Хәрби-космик көчләр һәм Стратегик максаттагы ракета гаскәрләренең сугышчан әзерлеге көчәйтеләчәк.

Сүз уңаеннан, оборона министры Сергей Шойгу узган ел ахырында министрлык коллегиясендә армиягә хәрби хезмәткә чакыру яшен – 21гә, ә чик яшьне – 27дән 30 яшькә кадәр күтәрү бурычын куйган иде.

«Омикрон» хөкем сөрә

Соңгы атнада Россиядә коронавирус йоктыру очракларының барысына да «омикрон» штаммы «гаепле». Роспотребнадзор хәбәр иткәнчә, 2023 елның икенче атнасында илдә чир ияртүчеләр саны 31 мең кешедән артып киткән. Бер атна эчендә COVID-19 йоктыручылар саны 40 процентка арткан.

Россиянең 75 субъектында чирләүчеләр саны арткан. 16 төбәгендә – ил буенча уртача күрсәткечтән күбрәк дәрәҗәдә. Россиядә бер үк вакытта грипп һәм коронавирус йоктыру очраклары да теркәлә. Белгечләр әйтүенчә, иммунитеты зәгыйфь кешеләр гадәттә шулай бик каты авырый.

Теркәүне җиңеләйтәләр

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе мобилизацияләнүчеләр һәм аларның гаиләләренең күчемсез милкен теркәү эшен тизләткән. «Кайнар линия» дә эшләвен дәвам итә. Ведомствода искәртеп үтелгәнчә, хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм аларның гаиләләре әгъзалары милеккә хокукны рәсмиләштерү мәсьәләсе буенча (843) 255-25-71 телефоны аша шалтыратырга мөмкин.

Шәхси йорт яки фатирны теркәү өчен Күпфункцияле үзәккә документлар тапшырып, Росреестрның теләсә кайсы бүлегенә теркәүне тизләтү турында гариза тапшырырга кирәк. Республика районнарында исә ведомствоның территориаль бүлекләренә мөрәҗәгать итәсе. Аларның адреслары, телефоннары белән Росреестрның рәсми сайтында (rosreestr.tatarstan.ru) танышырга мөмкин.

Теркәүне тизләтү турында гаризага мобилизацияләнүче белән туганлыкны раслаучы документлар: паспорт, туу, никахлашу турында таныклыкларның күчермәләрен кушып бирергә кирәк. Ә инде мобилизацияләнүне раслау өчен хәрби комиссариаттан килгән повестка яки башка документ күрсәтү шарт.

Эшлисе килгәнгә эш бар

Думага үсмерләрне 14 яшьтән эшкә алуны гадиләштерү турында закон проектын керткәннәр. «Авито Работа» үзәге мәгълүматларына караганда, узган елда Россиядә 14 яшьлекләр өчен эш буенча тәкъдимнәр – 59, Казанда 7 процентка арткан. Гыйнвар уртасына Татарстан башкаласында мәктәп укучылары өчен барлыгы 2800дән артыграк вакансия барлыкка килгән.

Үсмерләргә хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләү барыннан да ешрак тәкъдим ителә. 2022 елда Россия буенча тәкъдимнәрнең 24 проценты курьер эшенә туры килгән. Казанда мондый эш өлеше 9 процентка тигез. Шәһәребездә вакансияләрнең 5 проценты – консультант, промоутер (реклама кәгазе өләшеп йөрүчеләр), сәүдә залында эшләүгә карый. Вакансияләрнең 6 проценты – җитештерү өлкәсе буенча (төрүче).

Укучыларга шулай ук фитнес һәм матурлык индустриясендә вакансияләр саны арту күзәтелә. Казанда мондый эш урыннары өлеше 3% тәшкил итә.

Вакыйга

Көчле рухлыларның көче

КАЗАНДА МАХСУС ОЛИМПИАДАНЫҢ БЕРДӘМ УЕННАРЫ УЗАЧАК

Медаль өчен ярышу түгел. Башкалада Махсус Олимпиаданың Бердәм Уеннары узачак. Ил тарихы өчен тәүгесе, оештыру һәм үткәрү форматы буенча да моңарчы күрелмәгәне. Уеннарның әһәмияте нидә? Башкалага кемнәр киләчәк? Ни өчен ярышларны Татарстанга ышанып тапшырганнар? Оештыручылар журналистларга шул хакта сөйләде.

Кайчан: 2023 елның 21–27 гыйнвары.
Кайда: ачылыш тантанасы – «Казан Экспо» күргәзмәләр залында, ә ярышлар Татарстан һәм Казанның 14 корылмасында узачак. Катнашучылар Универсиада авылы һәм «Свияжские холмы» комплексында яшәячәк.

Шунысын да искә төшерергә кирәк: Махсус Олимпиада 2021 елның февралендә Швециядә узарга тиеш иде. Әмма әлеге ил ярышларны үткәрүдән баш тартты. Шуннан соң уеннарны Россиядә оештырырга тәкъдим ителде. Ярышлар үзәге итеп, билгеле, Казанны сайладылар.

Тик былтыр ук узасы чараны кабат кичектерергә туры килде. Быел инде киртәләр булмас, оештыручылар да сынатмас төсле. Спортчылар гыйнвар аенда көч сынашачак. Спортның 11 җәйге һәм 7 кышкы төрләре буенча ярышлар көтелә.

Махсус Олимпиаданың Россиядәге президенты Ольга Слуцкер да: «Без инде әзер», – дип ышандырды.

Аннан бигрәк Казандагы оештыручыларга ышанычы зурдан икән. Чөнки безнекеләр әле бер генә чараны да начар итеп оештырганы юк. «Мин бу җәһәттән тыныч», – диде Ольга Слуцкер.

Олимпиада янына «махсус» дигән сүз өстәлгән икән, бу ярышларның үзенчәлекле булуын да аңларга кирәк. Монысында акыл ягыннан тайпылышлары булган спортчылар ярыша. Уеннарның максаты – аларның уңышка ирешергә сәләтле булуларын күрсәтү, җәмгыятьтә үз урыннарын табарга булышу. Ярышта гимн да җырламыйлар, әләм дә күтәрмиләр. Көч сынашу да медаль йә бүләк өчен түгел, ә, бәлки, гыйбрәт алу өчендер.

Ольга Слуцкер сүзләре белән әйткәндә, сәламәтлеге ягыннан кимчелеге булганнарны ярышларсыз калдырып, спорт бәйрәменнән мәхрүм итү бер дә дөрес булмас иде.

– Без мондый форматны дөньяда беренчеләрдән булып уйлап таптык, җәйге һәм кышкы уеннарны берләштердек. Казанда заманча спорт инфраструктурасы күп. Бу безгә мондый дәрәҗәдәге ярышларны үткәрү мөмкинлеген бирә, – дип аңлатты ул.

Беренчеләргә һәрчак авыр. Ярышларны үткәрү дә билгеле бер куркыныч, шик уятырга мөмкин. Әмма, Ольга Слуцкер әйтмешли, курыккан кешеләр бернәрсәгә дә ирешми.

Инде сан теленә күчик. Казандагы Уеннарда катнашу өчен илнең 59 төбәгеннән һәм Белоруссиядән спортчылар җыелачак. Барлыгы 1,5 мең катнашучы килер дип көтелә. Чараны оештыруда, катнашучылар белән бергә булырга 800дән артык волонтер ярдәмгә киләчәк.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

tatarstan.ru

Михаил МУРАШКО, Россия сәламәтлек саклау министры:

Пандемия халыкның репродуктив системасына нык тәэсир итте. Әлегә коронавирусның кимүе күзәтелсә дә, вакцина ясату актуаль булып кала. Бала алып кайтырга теләүче хатын-кызлар һәм ир-атлар, шулай ук авырлы ханымнарга коронавируска каршы вакцина ясатуны дәвам итәргә кирәк.

(«РИА Новости»)

РОССИЯДӘ – УҢЫШ

Росстат 2022 елда Россия буенча күпме күләмдә уңыш җыеп алынуы турында мәгълүмат белән уртаклаша. Сүз уңаеннан, 2021 ел белән чагыштырганда 2022 елда 26,7 процентка артыграк уңыш җыелган.

Бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар >> 153,83 млн тонна

Бодай >> 104,44 млн тонна

Арыш >> 2,2 млн тонна

Солы >> 4,56 млн тонна

Карабодай >> 1,2 млн тонна



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЕМ ГАЕПЛЕ: НАМУСЫН ЮГАЛТКАН ХӘКИММЕ, ГАДӘТТӘН ТЫШ САЛКЫННАРМЫ?

Үткән тәүлекләрдә Урта Азиядә гадәттән тыш хәл туды: аномаль салкыннар башланып, энергия кризисы мәйданга чыкты. Бигрәк тә Үзбәкстан башкаласы Ташкентта кешеләр авыр хәлдә калдылар: җылылык һәм газ бирү туктатылды, электр энергиясе өзелде. Урамда исә 20 градуска җиткән салкыннар иде. Әле мин менә бу юлларны язганда да, сишәмбе иртәсендә Ташкентта ун градуслы салкын күрсәтә. Газ һәм электр энергиясен экспортлаучы Үзбәкстан көтмәгәндә аларның үзендә дә җитмәвенә дучар булды. Европа кышкы эсселектән рәхәт чиккәндә, кояшта кызынырга тиешле Урта Азия, туңып, калын киемнәргә төренде, кешеләр, урамнарга чыгып, ашарга әзерләү өчен учаклар якты. Хәл бик катлаулы һәм киеренке иде. Эш шуңа барып җитте: Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиев, Сингапурда башланган өч көнлек визитын кыскартып, бер көнгә генә калдырды. Ташкент хәкиме Җаһангир Артыкхоҗаев илдән чыгып качарга дип аэропортка юнәлде, әмма Дәүләт куркынычсызлыгы хезмәте тарафыннан тоткарланды. Президент аның турында: «Намусын югалткан һәм җирдән аерылган», – дип белдерде.

Беренче карашка, монда кемгә үпкәлисең, андый аномаль салкыннар вакытында төрле хәл булырга мөмкин бит инде, дип уйларга була. Әмма газета хәбәрчесе Урта Азия республикаларындагы энергетика белән бәйле вазгыятьне яхшы белә. Көзен көннәр әле җылы торганда да, мәсәлән, ул Кыргызстан шәһәре Оштан даими рәвештә ут өзелүе турында зарланулы хәбәрләр алып торды. Вазгыять Үзбәкстанда да шул чама иде. Электр бирү шулкадәр начар: өйдә суыткыч тоту файдасыз. Бу хакта үзбәкләр сөйли иде.

Вазгыятькә бәйле киңәшмәдә шуңа күрә Мирзиев бәладә салкыннарны түгел, чиновникларны гаепләде. «Нефть-газ һәм энергетика системаларында соңгы берничә айда гына 192 коррупция факты ачыклану системаның эчтән җимерелүе турында шаһитлык бирә», – диде.

Үзбәкстаннан газета хәбәрчесе турыдан-туры алган хәбәрләр шомлы иде. «Ташкентта ярсыган кешеләр Юнусабад һәм Шайхантур районнарының Электр челтәрләре бинасын чолгап алдылар», – дигән хәбәр килде. Андый вазгыятьтә халык ярсуы бик куркыныч нәрсә ул. Башкала мэры эшеннән алынды, аның белән Куркынычсызлык хезмәте шөгыльләнә. Моннан тыш энергетика министры урынбасары Шерзод Хоҗаев, «Иссиклик электр станцияләре» идарәсе рәисе Фәрход Абдурахманов эш урыннары белән саубуллаштылар, Ташкентның тагын өч районы мэрлары эштән алынырга тиешләр иде, әмма аларны «вазыйфа башкаручы» статусында калдырып тордылар.

Премьер-министр Ариповка һәм энергетика министры Мирзамәхмүдовка, салкыннар булуга карамастан, бурычын түләмәгән кешеләрнең утын һәм газын өзәргә рөхсәт ителде. Илдә электр энергиясен куллану иң югары ноктага – 250 миллион кВт сәгатькә җитте, диделәр. Үзбәкстанның электр челтәрләре андый киеренкелеккә чыдарлык түгел.

Россиядә

БЮДЖЕТ ҖИМЕРЕЛМӘС, ӘММА ПРОБЛЕМАЛАР ҖИТӘРЛЕК

2022 елны уңышлы гына үтеп (бюджет керемнәре көтелгәннән күбрәк булды), Россия яңа катлаулы елга аяк басты. Быел, шик юк, акча-финанс мәсьәләләре катлаулырак булачак. Углеводородлар сәүдәсе безгә үткән елдагы комфортлы шартлар тәэмин итмәячәк. Акча җитмәү 2022 елның икенче яртысында ук сиздерә башлады инде. Бюджет дефициты кварталдан кварталга арта барачак. Финанс министрлыгы тишекне финанс мендәрен сүтеп тулыландыру турындагы карарны кабул итте инде. Валюта резервлары (асылда Кытай юаньнары) сатуга чыгарылачак. Кытлык чакта, резервларың булу шәп инде ул, әмма аларны сату проблемадан коткарып кына калмый, проблема тудыра да. Валюта сата башладыңмы, сумның курсы өскә китә. Бу – резервлар сумнарда исәпләгәндә кими дигән сүз. Әйтик, йөз долларлык резервың булса, сум курсы 75 булганда, син аны сатып, 7500 сум акча аласың, курс 65 булса, 6500не генә. Финанс министрлыгы, резервларны сатканда, менә шундый проблемага килеп терәлә. Аны хәл итү өчен, күп итеп акча басарга була, билгеле. Бу – гарантияләнгән инфляция дигән сүз. Хөкүмәт болай да кызыклы ат йөреше ясап ята икән. Бюджет дефицитын каплау өчен, милли байлык фондыннан ике триллион сум акча ала. Дефицит әлегә 3,2 триллион сум булыр дип көтелә, әмма җитмәүчелек ике тапкырга якын үсәргә дә мөмкин. Дөресрәге, мөмкин, дип түгел, үсәчәк дип уйларга кирәк. Ләкин теге милли байлык фондындагы акчаның туңдырылган өлешен тотарга ниятли икән федераль түрәләр. Туңдырылган өлешне безгә бирмиләр инде бирүен, әмма югарыдагылар хәйләкәр бер адым ясыйлар: туңдырылган долларлар күләмендә рубльләр басалар. Инфляция өчен кирәкле туфрак әзерлиләр ягъни.

Ләкин базарда барысы да начар түгел. «Российская газета» төзелеш материалларына бәяләр төшү хакында яза. Акча кытлыгы нәтиҗәсе бу. Бу яктан караганда, финанс кытлыгы алай начар нәрсә түгел ул, дефляциягә китерә. Дефляция шартларында, акчаны исраф итми тотарга өйрәнгән халык ота: кулында акчасы барларга төзелеш алып бару җиңеләя. Гомумән алганда, төзелеш күләме кими, әлбәттә (бәяләр шуңа күрә төшә бит инде), әмма аягын юрганына карап сузучылар андый шартларда үзләрен иркен хис итә.

Россиядән бүген 8 миллион кеше чит илгә чыга алмый, чөнки бурычлары чабудан тарта. Бурычын түләмәүчеләргә чикләр ябык бит. Сан рекордлы. Бурычларның 80 проценты – ипотека кредиты, ди Үзәк банк. Ел башыннан Үзәк банк кредит бирүгә лимит керткән, хәзер бурычка алу мөмкинлегенә гражданнарның 25 проценты гына ия. Калганнар алса, түли алмаячак. «Российская газета», ил халкының яртысыннан күбрәгенең саклык акчасы юк, дип яза. Яңа финанс елына без менә шул хәлдәрәк аяк басабыз: бюджетта да кытлык, кесәләрдә дә җил уйный. Әмма хәтта хөкүмәтне тәнкыйтьләргә яраткан икътисадчылар да, триллионнар «силовик»ларга һәм фәкыйрьләргә бүленде, ләкин бюджет җимереклегенә кадәр эш барып җитмәс, диләр. Моны социаль йөкләмәләр үтәләчәк дип аңлыйк.

НИГЕЗДӘ – «КАРА АЛТЫН»

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Планетаның сыек углеводородлары запасларын нәтиҗәле үзләштерү» дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәкнең Күзәтүчеләр советы утырышында катнашты. Искәртәбез: Рөстәм Миңнеханов әлеге үзәкнең халыкара Күзәтүчеләр советы рәисе булып тора.

Катнашучыларны сәламләп, Рөстәм Миңнеханов Татарстанда фәнни-технологик үсеш өстенлекләре буенча Россиядә барлыкка килгән дөнья дәрәҗәсендәге 10 фәнни үзәкнең берсе эшләвен искәртте. «Республикадагы үзәк эшчәнлеге углеводород чималы ятмаларын эзләү, табу һәм үзләштерүнең нәтиҗәле технологияләрен булдыруга юнәлдерелгән. Алар илне газ һәм нефть запасы белән тәэмин итәргә тиеш», – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, бу (бигрәк тә яңа геосәяси вазгыять кысасында) Россиянең икътисадый иминлеген тәэмин итү өчен гаять мөһим. Ул хисап белән чыгыш ясаучыларны да углеводородлар эзләү һәм чыгару буенча яңа технология һәм алымнарны куллану мәсьәләләренә аерым игътибар бирүләрен сорады. Аның сүзләренчә, үзәк уйлап тапкан һәр нәрсә иң элек республикада кулланылырга тиеш. Әйтик, «Татнефть» компаниясе объектларында йә булмаса кече нефть компанияләрендә.

– Нефть чыгару сәнәгате якын киләчәктә дә Татарстан икътисадының нигезен тәшкил иткән тармакларның берсе булып калачак. Аның тулай төбәк продуктын, бюджет системасы керемнәрен формалаштыруга керткән өлешен бәяләп бетерү дә кыен. Шулай итеп, үзәкнең эшчәнлеге республикабызның фәнни-технологик үсеше өчен генә түгел, ә социаль-икътисадый үсеше өчен дә зур әһәмияткә ия, – диде Рөстәм Миңнеханов.

БЕЛЕШМӘ

«Планетаның сыек углеводородлары запасларын нәтиҗәле үзләштерү» дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәк консорциум форматында эшчәнлек алып бара, аның координаторы – КФУ. КФУдан тыш, консорциум составына нефть-газ ятмаларын өйрәнү һәм нефть чыгаруның яңа технологияләрен булдыру өлкәсендә лидерлар керә: Сколково фән һәм технологияләр институты (керн һәм пласт флюидларын тикшерү); Уфа дәүләт нефть техник университеты (углеводород ятмаларын эзләү һәм эшкәртү); Губкин исемендәге Россия дәүләт нефть һәм газ университеты (пласт-коллекторларның нефть бирүчәнлеген арттыру технологияләрен эшләү).

Иминлек сагында

3000нән артык хокук бозу очрагы, 200гә якын тоткарланган җинаятьче, законсыз сакланган 1900 берәмлектән артык корал. Татарстан буенча Росгвардия идарәсенең узган елгы хәрби хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләре әнә шундый. Бу хакта идарәнең йомгаклау коллегиясендә Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин җиткерде.

Премьер-министр ассызыклаганча, халыкның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре һәрвакыт өстенлекле булып кала.

– Росгвардиянең Татарстан буенча идарәсе бүлекчәләре һөнәри яраклылык һәм белем буенча яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. Хезмәткәрләр хәрби хәрәкәтләр зонасында да куелган бурычларны лаеклы үтиләр. Шәхси сак предприятиеләре эшчәнлегенә аерым игътибар бирергә кирәк. Беренче чиратта, мәгариф учреждениеләрендә балаларыбызның иминлеген тәэмин итүчеләренә, – диде Алексей Песошин.

Җәмәгать тәртибен саклау, терроризмга һәм экстремизмга каршы көрәш алып бару, оператив-профилактик чараларда катнашу. Узган елда ведомство алдында шундый бурычлар торган. Нәтиҗәләр куандырырлыкмы? 2022 елда Росгвардия хезмәткәрләре республикада 3 меңнән артык хокук бозуны туктаткан. Оператив чаралар вакытында 195 җинаятьче тоткарланган. Шуларның 64е – җинаять кылуда шикләнелүчеләр, шул исәптән өчесе – экстремистик һәм террорчылык юнәлешендәге җинаятьләр өчен. Патрульлек вакытында 472 җинаять, 3 меңнән артык административ хокук бозу ачыкланган, эзләүдә булган 38 кеше тоткарланган.

Шартлату техникасы буенча белгечләр куркыныч предметлар булуга 470 объектны тикшергән, 14 шартлаткыч әйбер табылган һәм зарарсызландырылган. Ведомстводан тыш сак бүлекләре төрле милек формасындагы 15 меңнән артык объектны, шулай ук 34,5 меңнән артык гражданнарның яшәү урынын саклаган.

Корал тоту мәсьәләсенә килгәндә, лицензия-рөхсәт бирү эше хезмәткәрләре контролендә 430 шәхси сак оешмасы һәм 43 меңнән артык кеше тора. Алар кулында – 75 мең берәмлектән артык ату коралы. Узган ел Росгвардия идарәсе хезмәткәрләре республикадагы барлык корал хуҗаларын тикшергән. Нәтиҗәдә саклау кагыйдәләрен бозган өчен гражданнардан 437 корал берәмлеге һәм 700дән артык патрон, юридик затлардан – 8 корал берәмлеге һәм 660 патрон алынган. Гражданнар ирекле рәвештә аларда законсыз сакланган 1900 берәмлектән артык корал тапшырган.

Ләйсән САФИНА

Көчле рухлыларның көче

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, бу чара Татарстанда булган мөмкинлекләрдән файдаланырга, бу өлкәдә алга таба ничек эшләргә икәнен аңларга ярдәм итәчәк. Спорт бәйрәменнән калган мирас исә Татарстан өчен генә түгел, ил өчен тулаем әһәмияткә ия. Сүз бит әле, алданрак язганыбызча, корылмалар турында гына бармый. Бу ярыш Татарстанга интеллект үсеше үзенчәлекләре булганнар белән эшләү буенча тәҗрибә алу мөмкинлеген дә бирәчәк. Ә бу исә республикага бөтен ил күләмендә инклюзив җәмгыять үсеше өчен җитди этәргеч булмагае.

Татарстанның спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов әйтүенчә, республика данын 95 кеше яклаячак. Алар җиңел атлетика, бадминтон, волейбол, чаңгы, дзюдо, теннис, йөзү һәм спортның башка төрләре буенча ярышларга әзерләнә. Татарстан командасына Казан, Мамадыш, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Кама, Менделеевск һәм Минзәләдән катнашучылар да кергән.

Аңлашыладыр инде: ярыш Россия субъектларындагы спортчыларны гына колачлаячак. Хыялда исә ярышларны даими итү дә, бөтен дөньядан спортчыларны җыю да.

– Тормыш бер чак җайланып китәр, башка илләр белән дустанә мөнәсәбәтләр корылыр, аралашып яши башларбыз. Шул чагында Уеннарга да төрле илләрдән катнашучылар килер, – дип өметләндерде Ольга Слуцкер да.

Ә әлегә оештыручылар да бу Уеннарны килеп күрергә өнди. Әлеге дә баягы гыйбрәт өчен булса да. Чараны «Матч.Страна» каналыннан күрсәтү дә ниятләнә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

tatarstan.ru

ҖИРНЕҢ КАДЕРЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

Нәтиҗә

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының еллык коллегиясендә төп фикер әнә шушы тирәдә әйләнде. Кадерсез җирләр, аларны исәпкә алу һәм күпбалалы гаиләләрне җир белән тәэмин итү. Елга йомгак ясаганда шушы һәм башка мәсьәләләргә аерым тукталдылар.

Ятим балаларга бирелә торган торак мәсьәләсе дә игътибар үзәгендә булды. Узган ел шундый 600 бала үз куышына ия булган. Бу эш быел да дәвам итәчәк. Тик фатир булу белән генә түгел, аны карап, тәртиптә тотарга, торак-коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләп барырга да кирәк бит әле. Тармак министры сүзләренчә, бу мәсьәлә буенча проблемалар шактый зур.

Бүген Татарстанда 71 меңнән артык күпбалалы гаилә бар. Аларның 48 меңнән артыгы җир алу буенча кадастр учетына куелган. Әлегә 26 меңнән артык гаилә җир участоклары белән тәэмин ителмәгән.

– Гомумән алганда, җир кишәрлекләре белән тәэмин ителеш канәгатьләндерерлек. 24 районда күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен тулысынча биреп бетергәннәр, – диде Фәнил Әһлиуллин.

Алабуга, Алексеевск, Буа, Мөслим, Чистай, Тәтеш районнарында җир участогы белән тәэмин ителеш 90–99 процентны тәшкил итә. Шул ук вакытта кайбер районнарда бу эш сүлпән бара. Мәсәлән, Бөгелмә (тәэмин ителеш – 57,86 процент), Лениногорск (61,72), Әлмәт (62,63), Кукмара (64,34), Яшел Үзән (65,90), Биектау (72,25), Баулы (73,57), Арча (75,31), Лаеш (76,74), Түбән Кама (78,94) районнарында җир участогын көтүче гаиләләр күп.

vk.com

– Кайбер районнарда йорт салырга мөмкин булган җирләр юк дәрәҗәсендә. Аеруча Казан һәм Чаллыда вазгыять катлаулы. Аларда 16 меңнән артык җир участогы җитми, – диде министр.

Билгеле булганча, узган ел төрле ведомстволарның җир участокларын һәм күчемсез милекләре турындагы мәгълүматларын берләштерүче бердәм цифрлы платформага (мәгълүматларның илкүләм системасы – НСПД) нигез салынды. Монда Татарстан пилот проект буенча кертелде. Тик әлегә республика күрсәткечләр буенча мактана алмый. Электрон мөрәҗәгатьләр саны буенча без пилот төбәкләр арасында нибары 30 нчы урында гына торабыз.

– Ел дәвамында җирле үзидарәләр тарафыннан активлык сизелмәде. Бары тик Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның тәнкыйтеннән соң гына бераз активлык күренде. Күчемсез бердәм дәүләт реестрын, гомумән, мәгълүматларның илкүләм системасын тутыру, Росреестрга түгел, ә беренче чиратта сезнең үзегезгә кирәк. Аерым алганда, бу эшләрне тизләтер, инвесторлар җәлеп итәр өчен кирәк, – дип мөрәҗәгать итте җирле үзидарәләргә Росреестрның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова.

Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Илнур Галиев кулланылышта булмаган авыл хуҗалыгы җирләрен киметмәү максатыннан узган елның язында 850 тикшерү узганын әйтте. Ул вакытта 1 меңнән артык закон бозу очрагы теркәлгән. Кулланылышта булмаган 101 мең гектар җир булуы ачыкланган. Октябрь ахырында аларның 36 мең гектары кулланылышка кертелгәнлеге билгеле булган.

– Кайбер районнарда җирләр авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә арендага да бирелмәгән, иген дә чәчелмәгән. Сүз 15 мең гектар турында бара. Әйтик, 15400 гектар җирдә уҗым культуралары чәчелгән булса, 555 млн сумлык уңыш җыеп алган булыр идек. Ә рапстан 1,5 млрд сум керем кергән булыр иде. Бу мәйданнарда, мәсәлән, Яңа Чишмә районындагы терлекләргә ел дәвамында җитәрлек азык әзерләп булыр иде, – диде Илнур Галиев.

Хәер, узган елның җәендә җиргә саксыз караучыларга кагылышлы законга үзгәрешләр кертелгән иде. Аның нигезендә, моннан соң җир хуҗаларына аны максатчан файдалануны махсус комиссия алдында дәлилләргә туры киләчәк. Өч ел дәвамында җирне файдаланмаган җир хуҗаларыннан җирне тартып алу эше дә җиңеләйтелде.

Әлеге четерекле мәсьәләгә утырышта катнашкан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да басым ясады.

– Кулланылмый, максатчан файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы җирләре булу беркемне дә бизәми. Дәүләт Советы депутатлары, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты бу мәсьәләгә зур игътибар бирәчәк. Район башлыкларына да бу проблемага зуррак игътибар бирергә кирәк, – диде ул.

Моннан тыш, Фәрит Мөхәммәтшин барлык районнарның һәм шәһәрләрнең, авылларның чикләрен билгеләп чыгу эше ахырына якынлашуын әйтте.

– Бу мәсьәләдә вакыт-вакыт үзгәрешләр дә булуы бар, – диде ул. – Бигрәк тә күрше төбәк чикләренә кагылышлы мәсьәләдә. Ниһаять, очына чыгып, кирәкле документларга кул куелды. Киров өлкәсе белән чиктәш булган Кукмара буенча бер проблемалы участок калган иде. Тау чаңгысы комплексын җәелдерү өчен Киров өлкәсенең 60 гектар җирен Татарстан чиге территориясенә бирү турында сүз булды. Җиңел бурыч түгел иде, Президент бу мәсьәлә буенча Киров өлкәсе губернаторы Александр Соколов белән очрашты. Нәтиҗәдә җирне эшмәкәргә 49 елга арендага биреп тору буенча килешү төзелде.

Республикада дәүләт милкен файдалану һәм тормышка ашырудан алынган керем күләме узган ел **10,7** млрд сумны тәшкил иткән. Министр Фәнил Әһлиуллин сүзләре буенча, керемнәрнең **93,5** проценты җир участокларын арендага биреп тору хисабына алынган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЛИЛИЯ АППАКОВА:

«ХАЛЫКНЫ КӨЛДЕРЕРГӘ ТҮГЕЛ, ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘК»

Бүген сәхнәдә матур әдәби телдә сөйләү никадәр мөһим? Классик алып баручыларга, нәфис сүз осталарына ихтыяҗ бармы? Ни өчен яшьләр бу һөнәргә килергә теләми? Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе лектор-музыка белгече, Татарстанның атказанган артисты Лилия АППАКОВА белән әнә шулар хакында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Сезнең концертлар һәм төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр алып баруда 30 елга якын тәҗрибәгез бар. Элек концертлар ничек уза иде, хәзер нинди үзгәрешләр бар?

– Дәүләт филармониясендә 1996 елда эшли башладым. Классик концертлар элек тә, хәзер дә югары профессиональ дәрәҗәдә уза. Россиянең халык артисты Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Дәүләт халык уен кораллары оркестры үз юнәлешенә тугры кала, халык музыкасын, рус, чит ил классик көйләрен уйный. Оркестрның башкару осталыгы елдан-ел үсә, яңа кызыклы программалар барлыкка килә, жанрлар киңәя. Элек без татар концертларын да еш үткәрә идек. Әйтик, Габдулла Тукайның туган көненә багышланган кичәләр, Рөстәм Яхин исемендәге Халыкара классик музыка фестивале. Быел безнең оркестр үзенең 30 еллыгын билгеләп үтәчәк. Бу датага без инде узган ел ук әзерләнә башладык. Оркестрның музыка белгече буларак, мин Казан консерваториясендә узган Халыкара конференциядә оркестрның 30 ел дәвамындагы концерт эшчәнлеген анализлап, доклад белән чыгыш ясадым.

:: Классик алып баручыларга бүген ихтыяҗ бармы соң?

– Кызганыч, музыка белгече һөнәре соңгы елларда үз актуальлеген югалтты. Классик алып баручылар бүген юк диярлек. Әйе, һөнәр бик катлаулы, анда фән белән шөгыльләнергә кирәк. Музыка белгече концерт кына алып бармый, ә музыка сәнгате, жанрлар, композиторлар турында сөйләп, халыкны агарту буенча эш алып бара. Филармониягә килгәч, мин музыка сәнгате мэтрлары – Георгий Кантор, Светлана Захарова династиясен, аларның традицияләрен дәвам иттем. Консерваторияне тәмамлаган белгечләр йә музыка мәктәпләрендә укыта, бик сирәкләре фәнгә, лекторлыкка бара, татар фольклорын, музыкасын өйрәнә. Халыкка музыка турында сөйләү җиңел эш түгел. Лектор – мәгърифәтче, музыка өлкәсендә эрудицияле кеше. Ул һөнәри белемнәргә генә түгел, дикторлык сәнгатенә дә ия булырга тиеш. Музыкантларны илһамландыру, тамашачыларны кызыксындыру, аларга шатлыклы һәм якты хис-кичерешләр бүләк итү өчен текстны кызыклы, «тәмле» итеп тәкъдим итәргә кирәк. Концертны алып баручы музыка белгеченең төп максаты әнә шул. Папкадан гына укый торган алып баручылар бар. Мин моны кабул итмим. Мин үз текстларымны яттан өйрәнергә һәм текстка эмоциональлек өстәргә тырышам. Алып баручының матур, сөйкемле, үз харизмасы, артистлыгы булуы да мөһим.

:: Яшьләрнең һөнәргә килмәвенең сәбәбен нәрсәдә күрәсез?

– Заманында бу темага Казан консерваториясе ректоры Вадим Дулат-Алеев белән сөйләштек. Ул инде шул вакытта ук яшьләр һөнәргә килми, музыка белгечләре юк, дип әйткән иде. Әйтик, заманында без 14 кеше укып чыктык, ә хәзер бу бүлектә 2–3 студент укып йөри. Билгеле, яшьләр өчен бу акчалы һөнәр түгел. Алар концертлар алып бара башлый һәм берникадәр вакыттан соң бәйрәмнәр, туйлар алып баруга күчә. Бу гаҗәп түгел, чөнки ул өлкәдә акча эшләү мөмкинлекләре шактый күбрәк. Тик яшьләрнең дә һөнәргә килүләрен, традицияләрне дәвам иттерүләрен телим. Музыка бит ул тәрбияли, матурлый, рухи яктан тулыландыра. Иң авыр, катлаулы заманнарда кешеләр сәнгатькә мөрәҗәгать итә. Хәзерге вакытта нәкъ менә классик сәнгатькә тартылырга кирәк. Классика ул – мәңгелек.

:: Элек татар классик концертлары еш уздырыла иде, хәзер күбрәк рус һәм чит ил классикларына игътибар бирелә, дидегез. Бу ни өчен алай булды?

– Безгә, татар музыкасы концертларына билетлар начар сатыла, заллар тулмый, ихтыяҗ юк, диләр. Ә бит безнең Филүс Каһиров, Илүсә Хуҗина, Рөстәм Насыйбуллин, Рөстәм Асаев кебек Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин музыкасын белә һәм яратып башкара торган җырчыларыбыз бар. Рөстәм Яхинны гына алыйк. Аны бит гомер буе җырларга мөмкин. Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Сибгат Хәким шигырьләренә язылган көйләр нинди бай, төсмерле алар! Бүгенге заман авторлары да кимен куймый. Әйтик, яшь композиторыбыз Эльмир Низамов. Мин аны татар классикасын дәвам иттерүче дип атар идем. Шуның кадәр зур, бай репертуарыбыз бар, ә заллар тулмый, билетлар сатылмый, диләр. Моны ишетү сәер хәтта. Минемчә, бу традицияне елга бер тапкыр Габдулла Тукайның туган көнендә булса да, торгызырга, үзебезнең классикларның музыкасын уйнарга кирәк.

:: Ә нәфис сүз осталары калдымы? Сәхнәдә матур әдәби телдә алып баручылар да сирәк бит хәзер.

– Татар телендә аеруча да аз әле. Нигездә, концертларны йә җырчылар, йә театр артистлары алып бара. Бу – алар өчен тиз генә акча эшләп алу ысулы. Сүз эстрада концертлары турында бара, классик концертларда андый нәрсә юк. Сәхнәдә барысы да күңел ачу форматына күчә бара. Кешеләр җитди, уйландыра торган әйберләрдән баш тарта. Хәзер барысы да – җиңел формада. Танылган башкаручылар сәхнәдә ниндидер оятсыз анекдотлар сөйли. Минем өчен бу – бөтенләй кыргый күренеш. Әйе, аның модасы шундыйдыр. Ләкин мода һәм классик сәнгать барыбер дә ничектер кисешергә тиеш дип уйлыйм мин. Нәфис сүз осталарына килгәндә, безнең чын сәнгать сүзе остасы ул инде – Рәшит Сабиров. Үзебезнең буыннан Илдар Кыямовны аерып әйтер идем. Тагын бер үрнәк – Резедә Сәләхова, Рамил Вәҗиев. Бик оста итеп саф татар телендә алып баралар.

:: Сәхнәдә сәнгатьле уку, шигырь сөйләү кебек күренешләр дә онытылып бара кебек.

– Нәфис сүз осталыгын чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән бөек шәхесебез Айрат Арсланов башкаруында Тукай, Җәлил, Такташ, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан шигырьләре һәркемнең күңеленә үтеп керә иде. Хәзер бу матур традиция бездә югала бара. Заманча алып баручылар, нигездә, юмористлар һәм пародистлар. Аларны халык кабул итә, ярата.

Бүген кешенең фикерләү рәвеше, кыйммәтләре үзгәргән вакыт. Тамашачыны анекдотлар белән түгел, мәдәният, сәнгать белән тәрбияләргә кирәк. Без сәхнәдә классикага мөрәҗәгать итәргә, шигырьләр укырга тиеш. Кеше бу тәрбияне бездән алмаса, кайдан алсын?

Мин инде күп еллар үз һөнәремне, юнәлешемне үзгәртмим. Тамашачылар безгә тормыш проблемалары һәм борчулары турында онытып, күңелен ял иттерергә, илһам, рухи көч алырга килә. Аеруча өлкән яшьтәге буын яратып йөри.

:: Әниегез Сәйдә Аппакова – танылган абыстай, татар дөньясында күренекле шәхес. Бу юлны сайлавыгызда аның йогынтысы булмый калмагандыр.

– Мәгърифәтчелеккә, ораторлыкка булган сәләтем әнидән килә. Аның эстафетасын мин сәнгатьтә дәвам иттем. Минем әни – уникаль, тирән белемнәргә ия шәхес. Коръәнне, дини әдәбиятны бик күп укый һәм, иң мөһиме, бу белемнәрне башкаларга җиткерә. Әнигә хәзер 88 яшь, ул элеккечә актив, гел хәрәкәттә, Аллага шөкер. Аны республикабызның төрле шәһәрләренә, районнарына вәгазьләр, лекцияләр укырга чакыралар. Әни даими рәвештә «Тәртип» радиостанциясендә чыгыш ясый. Үз эшендә ул – бик кирәкле һәм минем өчен чын үрнәк. Мин аннан туктап калмаска, һәрвакыт алга барырга өйрәнәм.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Хәерле юл!

Кесәдә торсын!

Рульдә йөрүчеләрнең тагын бер мәшәкате кимеде. Хәзер юлда ЮХИДИ инспекторлары туктаткан очракта, ашыгып-кабаланып машина йөртү таныклыгын эзлисе юк. Кирәкле барлык документлар – телефонда. Кәгазь документларны үзең белән йөртергә кирәкме? Бу сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

«Дәүләт хезмәтләре Авто» рәсми кушымтасында машина йөртү һәм транспорт чарасын теркәү турындагы таныклыкларның электрон нөсхәләре барлыкка килде. Моны илнең Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгында да раслаганнар. Моннан ары инспекторларга онлайн «права»ны күрсәтергә дә ярый. Әйтүләренә караганда, бүген рульдә йөрүче 2 миллион 500 мең кешенең кесә телефонында «Дәүләт хезмәтләре Авто» кушымтасы бар инде.

Илнең Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлүчеләр өчен яңа кушымталы булуның беренди кыенлыгы да юк. Телефонга кушымтаны өстисең дә, бетте-китте! Интернетта кирәкле бөтен мәгълүмат саклана. Шул исәптән машина йөртү таныклыгының ике яклы фотосы да бар. Юлда ЮХИДИ хезмәткәре туктаткан очракта, кушымтаны ачып, «документларны күрсәтергә» дигән төймәгә генә басарга кирәк. Болай эшләгәндә экранда махсус QR-код чыгачак. Инспекторлар машина йөртүче турындагы бөтен мәгълүматны әнә шуннан «укыячак». Тик шунысы да бар: әлегә яңалык тәҗрибә рәвешендә эшли. Шуңа күрә ЮХИДИ хезмәткәрләре онлайн «права» күрсәтүче машина йөртүчеләрдән кесәдәге документларын да сорарга мөмкин, дип искәртә белгечләр.

– Яңалык турында ишеттем, тик мондый мөмкинлектән файдаланып караганым юк, – ди унбиш елдан артык машина йөртүче Марат Хәйруллин. – Мин ерак араларга йөреп, кибетләргә азык-төлек ташыйм. Юлга документларсыз чыгып китүне күз алдына да китермим. Түш кесәсендә машина йөртү таныклыгы бар икән, аны ник күрсәтмәскә? Интернет тотмаска яки телефонның сүнгән вакыты булырга да бик мөмкин. Кәгазьгә язылган ышанычлырак.

Таксист булып эшләүче Рамил Шәфигуллин әйтүенчә, онлайн «права»га ияләшәсе бар әле.

– Без цифрлашып беттек бит инде. Гел юлда булгач, ЮХИДИ хезмәткәрләре белән еш очрашырга туры килә. Онлайн «права»ны күрсәткәнем бар. Тик барыбер кәгазь документларны сорадылар. Яңалыкка ияләшү өчен вакыт кирәктер, – ди машина йөртүче.

ЮХИДИ мәгълүматларына караганда, машина йөртү таныклыгының электрон нөсхәсе барлыкка килү ул кәгазь документлар гамәлдән чыга дигән сүз түгел. Һәрхәлдә, юлда йөрү кагыйдәләренә үзгәрешләр керткәнче сабыр итәргә һәм үзең белән кәгазь документларны йөртергә туры киләчәк. «ЮХИДИ хезмәткәре туктаткан очракта, үзе белән машина йөртү таныклыгы булмаган автомобиль йөртүчеләргә 500 сум штраф каралган», – дип тә кисәтә юл сакчылары.

Сүз уңаеннан, җиңел машина йөртүчеләргә тагын бер штраф гамәлгә керергә мөмкин. Декабрьдән февральгә кадәр (февральне дә кертеп) җәйге резинада, ә июньнән августка кадәр (августны да кертеп) кышкысында йөрүне канун нигезендә тыймакчылар. Төбәкләргә әлеге вакыт чикләренә үзгәрешләр кертү мөмкинлеген бирү дә каралган. Яңалык быелның 1 мартыннан гамәлгә керәчәк дип көтелә. Штраф күләме – 500 сум.

Эльвира ВӘЛИЕВА

АГАЧ ЭШЕ САБЫРЛЫККА ӨЙРӘТӘ

Шөгыль

Агачка җан өреп, төрле-төрле эшләнмәләр тудыра. Зур өйләрне берничә мәртәбә кечерәйтеп ясап бирә. Карап торырга гына матур. Ә эшли башласаң, күпме сабырлык кирәк. Чаллы остасы Фоат Закиров яшерми: тормышта бик кызу кеше ул!

Фоат Закировның шәхси архивыннан

– Агач эшенә тотынгач кына сабырлык килә миңа. Күңелем тынычлана. Ә бит мин тормышта ут чыгара торган кеше. Миндәйләрне җиңәр шөгыль дә бар икән, – ди үзе. – Бигрәк тә борынгы әйберләр ясарга яратам. Соңгы елларда хәтерем начарланса да, балачак һәм яшьлектәгеләрне бик яхшы истә тотам. Ясыйсы әйберләрне дә күз алдына китерәм дә эшләп куям. Кешене хәзер искелек белән генә шаккатырып була. Борынгы йорт җиһазларын, көнкүреш кирәк-ярагын ясарга яратам, чөнки алар хәзер юкка чыгып бара. Элек кешеләрнең ниләр кулланганын яшь буынга күрсәтәсем килә.

Фоат абый агачтан мәчет, борынгы йорт җиһазлары, транспорт һәм башка сувенирлар ясый. Тумышы белән Саба районының Сабабаш авылыныкы ул. Заманында урманчы булып эшләгән. Мәктәпне тәмамлауга эшкә кергән. Әтисе дә бик оста кеше булган. Аның кулында балта уйнап кына торган. Фоат абый исә агач эшенә армиядә тотына. Үзе хезмәт иткән частьның макетын ясап бирүләрен сорыйлар аннан.

– Урманда эшли башлагач, мине Кукмара районына эшкә билгеләделәр. Ул чакта Нургали Миңнеханов кулы астында эшләдем. Әле дә сагынып искә алам үзен. Бик акыллы кеше иде. Оста җитәкче булды. Эштә нинди генә хәлләр булмасын, читкә чыгармады, үзе хәл итә иде. Гадел кеше. Эшләгәнне күрде, кешене үстерә белде. Заманында Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов белән дә мотоциклда җилдерергә насыйп булды. Ул чакта Рөстәм яшь кенә егет иде. Безгә практикага килде. Мин аны Кукмара районының Өркеш, Арбаш, Нырты авыллары урманнарына алып барып кайткан идем, – дип искә ала Фоат абый.

Шәргыя апа белән өйләнешкәч тә кордонда яши әле алар. Олы кызлары Гөлнар шунда туа. Аннары инде алар Чаллыга күченә. Балалар үстергәндә агач эшенә булган сәләт тагын ачыла. Фоат абый 2 нче гимназиягә балта остасы булып эшкә урнаша.

– Башта шырпыларны җилем белән ябыштырып, ярты метр биеклектәге «Сөембикә» манарасын ясадым. Аннары агачтан чана, көрәк, балта, тәгәрмәч, арбалар… Балалар бакчасы өчен хәтта кечкенә чәнечкеләр дә ясаган идем. Бүген инде эшләнмәләрнең саны 500дән артып китте. Төрле авыл мәчетләрен ясап үзләренә бүләк итәм.

Фоат Закиров якыннарының, дусларының туган көненә бүләк эзләп азапланмый. Тота да берәр истәлекле әйбер ясап бирә. Үз туган көненә Кол Шәриф мәчетенең макетын ясап куйган ул.

Шәргыя апа белән алар биш онык сөя. Инде малайлар әкренләп бабайларына ярдәм итә башлаган. Агачтан әйбер ясарга хирыслыклары бар икән. Фоат абый гына, кулларын кисәрләр, дип пәке тоттырмыйча тора. Әмма өмете зур. Киләчәктә алар эшен дәвам итүчеләр булачак.

Оста лаеклы ялда булса да, гел хәрәкәттә. Күргәзмәләргә дә еш чакыралар. Аның кул эшләре туган авылында да саклана. Шактые – Лесхоз авылында урнашкан урман музеенда. Аларның тик торуларына борчыла икән. «Шкафта тузан җыеп ятмасыннар иде инде. Укучыларга күрсәтергә кирәк аларны. Вак кына эшләнмәләр булса да, аларда зур мәгънә ята. Тарих бит алар», – ди Фоат Закиров.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе функциональ диагностика табибы **Волкова** Валентина Валерьевнага, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникасы табиб-психиатры **Гәрәев** Илдар Хәйдәр улына, Казан шәһәренең «18 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе стоматология-ортопедия бүлекчәсе мөдире, табибы – стоматолог-ортопеды **Горячева** Марина Владимировнага, «Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең реанимация һәм интенсив терапия палатасы табибы – анестезиолог-реаниматологы **Мефодьев** Юрий Геннадьевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Моратова** Ләйсән Дамир кызына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ультратавыш ярдәмендә диагноз кую табибы **Мостафина** Татьяна Сергеевнага, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе анестезиология һәм реанимация бүлекчәсе мөдире – табибы – анестезиолог-реаниматологы **Нәҗипов** Айдар Илгиз улына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 6 номерлы анестезиология һәм реанимация бүлекчәсе табибы – анестезиолог-реаниматологы **Нәҗметдинов** Радик Рәвкать улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – стоматолог-терапевты **Сабурова** Зөлфия Дамир кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең нурланыш ярдәмендә диагноз кую бүлекчәсе мөдире – табиб-рентгенологы **Соколенко** Татьяна Юрьевнага, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок терапия кабинеты табиб-терапевты **Хәбибуллина** Гүзәл Илдус кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсе дәүләт заказын җайга салу бүлеге башлыгы **Аитова** Луиза Милес кызына, Казан шәһәре «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең клиника-диагностика лабораториясе фельдшеры-лаборанты **Әсәдуллина** Зөлфинә Вәзир кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча менеджеры **Баранова** Ирина Николаевнага, «Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Бимә фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – шәфкать туташы **Нуриева** Елена Әмир кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының кадрлар буенча урынбасары **Сәгъдиева** Алия Рәшит кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең өлкән шәфкать туташы **Ульянова** Мария Николаевнага **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары **Абашев** Альмир Рәшит улы, Казан шәһәренең «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры **Әхмәтов** Рамил Уел улы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г. Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 4 номерлы поликлиника бүлекчәсе шәфкать туташы **Мифтахова** Светлана Михайловна, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза буенча баш эксперты **Низамов** Ригель Хәләф улы, «2 номерлы стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы (Чаллы шәһәре) **Солтанов** Флер Хөҗҗәт улы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Шәвәлиев** Рафаэль Фирнаял улы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм халыкның санитария-эпидемиология ягыннан иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Казан шәһәренең дезинфекция станциясе» муниципаль бюджет учреждениесе баш табибы **Бикиев** Азат Әсхәт улы, сәламәтлек саклау өлкәсенә квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Минзәлә медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Хиражева** Люция Әхмәт кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының чараларны исәпкә алу һәм гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы **Рәхмәтуллин** Илдар Рәфкать улына **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы мелиораторлар коллективы һәм «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге, ТатНИИСХ агроландшафтлы игенчелек бүлеге мөдире, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган агрономы

ПУХАЧЕВ Анатолий Павловичның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт кына түгел бу

ak-bars.ru

Бисмиллалы хоккей

Казанда ислам илләреннән җыелган хоккейчылар алка сукты. Тәүге тапкыр оештырылган турнирның дәвамы да булачак. Шул нияттән Татарстан башкаласында ислам илләрендә хоккейны үстерү ассоциациясе төзеделәр. Боз һәм кәшәкә белән генә чикләнмичә, спортның әлеге төре башка юнәлешләрдә дә дуслыкны ныгытыр дип өметләнәләр. Татарстанның исә моның өчен тәҗрибәсе дә, абруе да бар.

Әлеге турнирның Казанда узуы гаҗәп түгел. Аны оештыру фикере «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit 2022» халыкара саммиты барышында барлыкка килде. Татарстан Россия белән ислам дөньясын бәйләп торучы күпер булып санала һәм республиканың бу юнәлештәге эшчәнлеге арта гына бара. Икенчедән, бездә дини ярышлар элек тә үтә иде. Хоккейның Татарстан өчен нинди әһәмияткә ия булганын исә әйтеп тә торасы юк. Кыскасы, теләк, ният һәм мөмкинлекләрне берләштереп, бисмилланы әйткәч, моңарчы күрелмәгән турнир узды Казанда.

«Татнефть-Арена» һәм Спорт сараенда узган очрашуларда барлыгы 17 команда бозга чыкты. Ир-егетләр турнирында Берләшкән Гарәп Әмирлекләре (БГӘ), Согуд Гарәбстаны, Иран, Оман, Бәһрәйн, Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан хоккейчылары, Алжир, Марокко һәм Ливан спортчыларыннан тупланган командалар уйнады. Татарстаннан исә ике команда чыгыш ясады. Хатын-кызлар ярышында Татарстан, Иран, БГӘ, Согуд Гарәбстаны һәм Бәһрәйннән җыелган гүзәл затлар алка сукты.

Бозда ярышып кына калмадылар, кунакларны Казан һәм Татарстан белән таныштырдылар. «Ак барс»та ничек итеп хоккейчылар әзерләгәнне дә күрсәттеләр. Чит ил вәкилләре соклану һәм гаҗәпләнүләрен яшермәде. Берәүләр күргәннәрен «әкият дөньясына сәяхәт» дип атаса, икенчеләре космонавтлар әзерләү үзәге белән чагыштырды. Ислам илләрендә «Ак барс»ның җанатарлары артасына да шик юк. Төп максат булмаса да, спорт дөньясында монысы да әһәмияткә ия.

Алка кертү һәм очко алу өчен генә җыелмадылар Казанда. Турнир тәмамланыр алдыннан узган очрашуда алга таба ни эшләргә, хоккейны ничек үстерергә дигән сорауларга җавап эзләделәр. Татарстанның Хоккей федерациясе президенты Наил Мәганов әйтүенчә, таныштык, хәзер инде элемтәләрне ныгытырга кирәк.

– Ислам илләре нигездә көньякта урнашкан. Без исә төньякка барып урнашканбыз. Хоккейны да башкаларга караганда яхшырак уйныйбыздыр. Әмма без үз тәҗрибәбез белән уртаклашырга, хоккейны үстерү өчен ярдәм итәргә әзер. Моның өчен шартларыбыз бар, – диде ул Идел буе физик культура, спорт һәм туризм университетында узган очрашуда. – Спорт кешедә иң яхшы сыйфатларны үстерә. Хезмәттәшлегебез аша күз алдына да китермәгән нәтиҗәләргә ирешә алырбыз дип уйлыйм.

Шулай итеп Казанда Ислам илләрендә хоккейны үстерү ассоциациясе төзеделәр. Оешманың президенты итеп Наил Мәгановны сайладылар. Ике вице-президент Азия һәм Якын Көнчыгыш илләре белән эшләячәк. Бу вазыйфага Кыргызстанның Хоккей федерациясе президенты Әнвәр Оморканов белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Кышкы спорт төрләре федерациясе президенты Хамәл Әл-Кубәйси билгеләнде. Әлеге оешма БГӘ, Согуд Гарәбстаны, Марокко, Алжир, Оман, Бәһрәйн, Иран, Монголия, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстан, Төркия һәм Татарстандагы Хоккей федерацияләре вәкилләрен берләштерә.

Хамәл Әл-Кубәйси хоккейдагы хезмәттәшлек спортта гына түгел, гомумән, Россия, Татарстан һәм гарәп илләре арасындагы элемтәләрне ныгытыр дип өметләнә.

– Хоккейны үсешкә этәргеч дип кабул итәбез, – ди ул. – Безнең илләрдә хоккей белән кызыксынучылар арта. Бергәләп яхшы нәтиҗәләргә ирешә алырбыз дип өметләнәбез.

Әнвәр Оморканов фикеренчә, Казахстанны исәпкә алмаганда, Азия, гарәп илләре хоккейда әле тәүге адымнарын гына ясый.

– Татарстанда күргәннәребез безгә үсәргә һәм тәҗрибә тупларга ярдәм итәчәк, – ди ул. – Соңгы вакытта сәясәтнең спортка тыкшынуын күрәбез. Сәясәттән ерак торып, без спорт тирәсендә берләшергә, хоккейдагы кардәшлегебезне бөтен дөньяга күрсәтергә, илләр һәм халыклар дуслыгы аша башкаларга үрнәк булырга тиеш. Татарстан әлеге турнирны оештырып нәк шуны күрсәтте. Алга таба катнашучылар тагын да күбрәк булыр әле.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ БУЛЫП КАЙТКАН ТАБИБ ИСКӘНДӘР НУРМИЕВ:

«ТОРМЫШКА БАШКАЧА КАРАРГА ӨЙРӘНӘСЕҢ»

Арабыздан беребез

Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендә эшләүче медицина хезмәткәре Искәндәр Нурмиев белән әллә нигә бер булса да сөйләшеп тора идек. Газета укучылары да бу егетне танырга тиеш: сәяхәт итәргә яратуы турында да, коронавируслы чорда «кызыл зона»да кешеләргә күрсәткән ярдәме турында да язган идек. Бер мәлгә тагын югалып торды бу. Сизмәдек түгел, сиздек. Чираттагы сәяхәтенә киткәндер дигән уй да килде башыбызга.

Соңыннан гына белдек: егет махсус хәрби операция зонасында булган икән! Төгәлрәк әйтсәк, бер төркем медицина вәкилләре белән берлектә республика карамагында булган Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтергә китә ул.

Азмы-күпме бер ай вакыт үтеп китә. Казанга кире әйләнеп кайткач, Искәндәрдән бу гамәле һәм анда күргәннәре турында сорашмый кала алмадык, билгеле.

Ният турында

Гомумән, Искәндәр – табигате белән тәвәккәл кеше. Шуңа да хәрби операция зонасына медицина хезмәткәрләрен җибәрү тәкъдиме булгач, каршы килми, шундук ризалаша. Хастаханәдә дә беләләр: өметләрне аклый, ышаныч яулап өлгергән, булдыра торган егет бит!

– Өлкән шәфкать туташы да: «Кемне җибәрәбез дигәч тә, иң элек башыма син килдең», – диде. Шуңа миңа килеп ирешкән тәкъдимнән баш тартмадым. Аннан, бу эшкә ир-ат хезмәткәрләрне генә җибәрәбез, диделәр. «Курку хисе булмадымы?» – дигәндә, гомумән, мин аның ни икәнен дә белмим. Шуңа борчылмадым да. Курыккан кеше бу дөньяның ямен-тәмен белми. Мин бу тормыштан һәм миңа килеп ирешкән һәр тәкъдимнән барысын да алып калырга тырышам, миңа бу кызык, яңа тәҗрибә, – дип сөйләде Искәндәр. – Бу тормышта кешеләрне дәвалау дигән һөнәр бар. Мин бу сүзләрне үзем дә еш кабатларга яратам. Әлбәттә, әти-әнине, якыннарны бу хәбәр әллә ни куандырды дип әйтеп булмый. Кайгырдылар. Әмма һөнәремнең җиңел түгеллеген беләләр бит.

Август – сентябрь айларында Лисичанск шәһәрендә булалар. Беренчеләрдән булып әлеге шәһәрдә һәм якын-тирә калаларда яшәүчеләргә республиканың берничә дистәдән артык медицина хезмәткәре ярдәм күрсәтә башлый. Искәндәр – урта медицина хезмәткәре вазыйфасында.

Шартлар турында

Барлык уңайлыклары да булган заманча хастаханәне калдырып, бернәрсәсез калган җиргә эшкә китү, ягъни «комфорт зонасы»ннан чыгу ничек булган соң?

– Байкал күленә сәяхәт кылган, Эльбрус тавына менгән кеше буларак та, авырлыклардан куркып кала торган кеше түгел мин. Лисичанск шәһәренә якын булган бер калада яшәдек. Ә сырхауларны махсус җиһазландырылган модульле «КамАЗ»ларда кабул иттек. Лисичанск шәһәрендә күперләр җимерек һәм юллар начар булу сәбәпле, безгә шуннан сырхауларны алып киләләр иде, – ди Искәндәр. – Татарстан табиблары тулы медицина ярдәмен күрсәтте. Анда бездәгедәй шартлар юк бит. Медицина бик начар хәлдә. Әйтик, 70–80 яшьлек әбиләрнең үз гомерләрендә бер тапкыр да рентген ясатканы булмаган. Аның ни икәнен дә белми алар. Йә булмаса, 40 еллап буын протезларын алмаштырмаганнар. Кыскасы, ярдәм күрсәтү өчен 100 процент тырыштык. Әйтик, Казанда без хезмәт күрсәтсәк, монда дөрестән дә ярдәм иттек. Ул сизелә, без шуны аңладык.

Шул вакыт арасында барлыгы 700-1 мең кешегә ярдәм күрсәтергә өлгерәләр. Көненә 60ар кешене кабул итә торган чаклары була. Яшерми Искәндәр: бу сан белән горурлана да, шулкадәр кешегә ярдәм итә алуына куана да. Кан алу, хәрби шартларда кечкенә генә операция ясарга да туры килә.

> Әлбәттә, рәхмәт сүзеннән кала башкаларын да ишетергә туры килде. Әмма, нишләмәк кирәк, тормыш бит бу... Кайберәүләр күчтәнәчкә виноград алып килеп безне сыйлый иде. Шунысы да бар: без ярдәм күрсәткән кешеләрнең кайсылары икенче көнне үк сине ике куллап дошманнарга тапшырырга мөмкин.

Сәбәпләре дә бардыр инде. Искәндәр әйтүенчә, андагы вазгыять бик күңелсез. Күп нәрсә җимерек… Әйтик, күпләр учак җылысында гына җылынып көн итә. Көянтә белән су ташый (суы булса). Кешеләргә кояш һәм хәрби тавышлар белән бергә уяныргга һәм ятарга туры килә.

Искәндәрләргә дә колакны бик үк иркәләмәгән тавышлар астында эшләргә һәм көн итәргә туры килә. Чын хәрби шартлар, кыскасы. Алар яшәгән биш катлы тулай торакка да ракета төшкән булган. Бәхеткә, Искәндәрләр ул вакытта туган якка кайтып киткән була. Тулай торактан исә берни калмаган.

Тормышка караш турында

– Аннан кайткач, үзгәрәсең. Чын «перезагрузка» бу. Барып кайтуыма үкенмәячәкмен. Бу барып кайту миңа бик кирәк булган. Тормышның кадерен белә башлыйсың. Мондагы мәшәкатьләрнең мәшәкать үк түгеллегенә инанасың. Анда өч тапкыр ашасаң да, шат буласың… Нәрсәнең ни икәнен чамалый башлыйсың. Бөтен нәрсә чагыштыруда беленә, – ди Искәндәр Нурмиев.

Күпләр, бәлки, әңгәмәдәшебезне дан-дәрәҗә өчен йөри дип уйларга мөмкин. Искәндәр сүзләренчә, дан-шөһрәт казану өчен анда бармыйсың. «Тәкъдим булса, тагын барырга риза. Ике дә уйламаячакмын! Анда безнең ярдәм бик кирәк!» – ди әңгәмәдәшебез.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИСКӘНДӘРДӘН КИҢӘШЛӘР

- ✓ Хәрби хәрәкәтләр зонасында булганда иң төп киңәш – командирлар кушканны гына үтәргә, беркайчан да ачык утка чыкмаска.
- ✓ Бер белмәгән кешеләр белән аралашмаска, әңгәмә кормаска.
- ✓ Исемнәрне үзгәртеп сөйләшергә була.
- ✓ Кирәксезгә телефон кулланмаска. Бер ай да элемтәсез яшәргә бик мөмкин.

БҮЛӘККӘ... ЕЛГА ТАШЫ

Бик тә гаҗәеп төрле без – адәм балалары. Холык-фигыльләребез дә, төс-кыяфәтләребез дә. Шулай ук мөнәсәбәтләребез дә.

Кемдер урманга, кемдер диңгезгә гашыйк, кемдер тауларга мөкиббән, минем кебек дала-болынлыклар яратучылар да күптер. Башкортстанда яшәүче яшьлек дустым Чулпанның әнә ташларга исе китә (һәм ташларга гына да түгел). Затлы, кыйммәтле ташлар дип уйлый күрмәгез, юк, гади чуерташларга гашыйк ул, әлеге ташлар күренеп торган чиста күл-елгаларга да битараф түгел.

«Көмештәй чип-чиста сулы елга төбеннән күренәдер гәрәбәдәй чуерташлар. Истәлеккә алдым ташларын. Тәңкә чөйдем елтыр суына, мине сагынып, елгыр елгакай, кабат килеремне көтсен дип, – дип язган иде ул җәен үзенең «ВК»дагы битенә. – Минем елга, күл, диңгез, тау буендагы ташларга чын-чынлап исем китә. Барган җирдән һәрчак матур ташлар алып кайтам…»

Ташларга гашыйк икәнен белгән якыннары барган бер җирдән аңа… ташлар алып кайта. «Мин яраткан Якты күл буеннан миңа күчтәнәч алып кайттылар. Матур ташлар!!! Шатланганымны күрсәгез. Алтын-көмешкә, тәмле ашауларга исем китми. Әмма җирнең бер кисәге – бер ташында дөнья тарихы, сере, моңы, җылысы, гүзәллеге сакланган бит, шуны үз учларымда тою олы кинәнеч миңа…» – бу юллар да дустымның социаль челтәрдәге битеннән.

Бер елны аның гади бер әрем турында язганын укып, үзе әйткәндәй, «ушым киткән» иде. «Әрем исе, әрем тәме» дигән мәгълүм җыр турында язганда ул өзекне кулланган идем. Хәтерегездә яңартыр өчен берничә

юлын кабатлыйм: «Әремнәрем чәчкә атты. Әремнәрем димен, чөнки аларны туган авылымнан, тау артыннан күчереп алып килеп утырттым. ИНӘЙ төсе итеп… Исе китеп ярата иде шушы әремнәрне… Ул ярату миңа да күчкән… Үзләрен яратканны сизәләрдер, күрәсең – бакчам күрке булып күкрәп үсәләр, үткәндә дә, сүткәндә дә дигәндәй, кинәнеп иснәп, сыйпап узамын. Сары бөртек чәчкәләре йомарлангач, иң кадерле букет итеп, гади генә, әмма иң матур истәлек итеп саклаган вазага утыртам. Ел әйләнәсенә шушы чәчкәләрем йөрәккә уелган матур хатирәләрне җанландырып, ИНӘЙле, бәхетле мизгелләрне сагындырып, миңа карыйлар…»

Гади бер ташларда, гади бер әремдә шушы кадәр матурлык, хис, кичерешләр тояр өчен дөньяга, әйләнә-тирәгә нинди күзләр белән карарга кирәк икән?! Шөкер, андыйлар да бар арабызда. Кырыс чорда да кырысланмаган бу саф күңелле кешеләр сулар һава кебек кирәк ләбаса.

Балтачтагы бер танышым дәва үләннәренә гашыйк, алар белән мавыга. Үләннәрнең мең дә бер шифасын белә. Бөтен тирә-юньне басып, үзәкләргә үткән чүп үлән дип кенә белгән тигәнәкнең шифасы турында да искитәрлек итеп сөйли ул.

– Безнең өчен генә тигәнәк чүп үлән икән, кайдадыр бик кадерле, дефицит дәвалау үләне икән ул, – дип шаккатыра. – Моннан берничә ел элек Казахстаннан туганнан туган сеңлем кайткан иде. «Тамыры белән тигәнәк алып китәм», – дип һәммәбезне аптыратты. Баксаң, аларда тигәнәкнең чәнечкеләрен энә терапиясе сыйфатында киң кулланалар, шуннан бик күп авыруларга дәва табалар икән. Моның өчен тигәнәк чәчәгенең чәнечкеләнеп, пәрәвез сыман пленка белән капланган чагы кирәк икән. Алып китте туганым тигәнәкне төбе-тамыры белән! Бакчасына утыртты, күрше хатыны белән икәүләп бик кадерләп үстерүләре, тигәнәкнең шәп итеп үсүе турында телефоннан шалтыраткан саен сөйләп торды. Берчакны чак еламый гына, ни булган дисәм, баксаң, балакайның бакчасыннан тигәнәген төбе-тамыры белән казып, урлап алып киткәннәр! Ике елдан соң кайткач, тагын тигәнәк алып китәргә булды. Бу юлы инде бер целлофан пакет тутырып, орлыгын алып китте. Әй, рәхәтләнгәннәр тигәнәккә! Орлыгы күрше-тирәләренә дә, таныш-белешләренә дә җиткән…

Әйтәм бит, без, адәм балаларын, аңлап бетерә торган түгел. Үзебездә үскән тигәнәкне, әремне (һәм башкасын да) үләнгә дә санамыйбыз, инеш, күл, елга ташларын да, тирә-яктагы гади матурлыкны да күрмибез. Читтәге матурлыкка сокланабыз, гүзәллеген дә, дәвасын да читтән эзлибез…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 207

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+